УДК 821.512.145

*Р.К. Ганиева*

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МОДЕРНИСТИК ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН

В статье рассматривается творчество писателя, журналиста и общественного деятеля Фатиха Амирхана в контексте татарской модернистской литературы начала XX века.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литературы начала XX века, модернистская литература.

Татар халкы үзенең тарихи барышында ике мәртәбә Ренессанс баскычы аша үтте. Беренчесе – урта гасырларда, мөселман мәдәнияте, Коръән тәгълиматы белән берегеп яшәгән заманда. Бу – халкыбызның Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда империясе, Казан ханлыгы кебек дәүләтләре булган чор. Өч йөз ел дәвамында колониаль бәйлелектә интеккәннән соң, XIX гасырның уртасыннан иҗтимагый һәм рухи төшенкелектән уяну, тернәкләнү, күтәрелү еллары башлана, ә инде XX гасыр башыннан аурупалашуга, җәдитләшүгә, милләткә хезмәт итүгә йөз тоткан, халкыбызның дини, сәяси, икътисади, мәдәни-әдәби үсешендә моңарчы һичкайчан күзәтелмәгән киң колачлы Икенче Яңарыш хәрәкәте мәйданга чыга. Әдәбият мәйданына татар милләтенең бәхете өчен җанатар Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый кебек даһилар, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Гафур Коләхмәтов кебек зур талантлар килә. Алар арасында «Җәдитчелек – Яңарыш» (Надир Дәүләт) әдәбиятына, аның алтын хәзинәсен тәшкил иткән төрледән төрле модернистик алым, стиль-агым, юнәлешләргә юл ачкан күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист-журналист, прозаик, драматург, тәнкыйтьче, тәрҗемәче Фатих Әмирхан да (1886–1926) бар иде. Иң элек ул урта гасыр Шәрекъ, шул исәптән, татар әдәбиятларында озак гасырлар дәвамында яшәп килгән, әдәби иҗатта иҗтиһад итү мөмкинлекләрен чикләгән тәкълидчелек, канунчылык, дистәгә якын төре булган нәзыйрәчелекне Америка, Аурупа, рус әдәбиятларында киң кулланылышта булган акмеизм, аң агымы, импрессионизм, концептуализм, символизм, экзистенциализм, экспрессионизм, фрейдизм кебек модерн күренешләрен татар әдәбияты җирлегендә сынап карый, Шәрекъ классикасы казанышларын ауропачыл реализм һәм романтизм эстетикасы белән аерылгысыз бербөтен итеп синтезлап, бөек экспериментатор буларак чыгыш ясый һәм гамәлгә кертә. Әдипнең замандашлары, шул исәптән,

күренекле әдәбият галиме Җамал Вәлиди болай дип язды: «...ул татар әдәбиятын заман теләгенә муафикъ бер калыпка, Көнбатыш әдәбияты калыбына салды, аңа җитди бер форма бирде, телне, өслүбне нечкәләп эшкәртүче булды. ... Ф. Әмирхан нәфис әдәбиятыбызны гарәбләштерүдә иң алда чыгучы һәм киң юл ачучыдыр» [Фатих Әмирхан..., б. 41].

Ф. Әмирханның төп идеалы озак гомерләр дәвамында феодаль торгынлыкта яшәгән татар кешесен «хакыйкый европеец», абруйлы репутациягә ия шәхес итеп тәрбияләү. «Яшьләр колагына бер сүз» (1908) дигән чыгышында ул болай дип язды: «Бездән мәгыйшәт эш вә эшлеклелек таләп итә. Бездән мәгыйшәт хакыйкый (чын) европеец булуыбызны таләп итә». «Аяклары бәйле Прометей» гомеренең соңгы көннәренә кадәр үзенең бу шигаренә турылыклы булып калды, әдәби барышыбызга модерн ысулы белән язылган берсеннән-берсе асыл әсәрләр бүләк итеп китте. Аларның кайберләре турында үзебезнең фикерләрне укучыга да тәкъдим итәбез.

* * *

Фатих Әмирхан (1886–1926) – һәм реалист, һәм романтик язучы. Бер үк вакытта аның әсәрләрендә сәнгатьчә фикерләүнең бу ике төре төрледән-төрле модернистик алымнар белән дә мөнәсәбәткә керә. Аларның күбесен әдип Көнбатыш һәм рус әдәбиятлары, аеруча Л.Андреев белән А.Чехов иҗатлары аша кабул итә.

XX йөз башы татар әдәбиятына, шул исәптән Фатих Әмирхан иҗатына зур йогынты ясаган рус язучыларының атаклысы – Леонид Андреев (1871–1919).

Мәгълүм булганча, экспрессионизм (французча – «экспрессио» – тәэсирлелек) өчен хас төп сыйфатларыннан берсе – караңгы, ямьсез сурәтләр, натуралистик тасвирлар, символлар, бәяләмәләр ярдәмендә кешенең субъектив дөньясын, аның кичерешләрен бик тә киеренке, гомумән, яшәешне тәмугъ, фаҗига итеп гәүдәләндерү.

1909 елда Фатих Әмирхан Леонид Андреевның экспрессионистик стильдә язылган «Асылган җиде кешеләр» («Рассказ о семи повешенных») хикәясен тәрҗемә итә һәм бастырып та чыгара.

Язучы Леонид Андреев та, тәрҗемәче Фатих Әмирхан да үлем җәзасы көтеп төрмәдә яткан биш террористның, ике җинаятьчененең эчке халәтләрен экспрессионистик алымнар ярдәмендә акылдан шашу дәрәҗәсенә җиткереп тасвирлый. Җинаятьче уголовниклар инде үзләренең кеше икәнлекләрен дә онытканнар. Мәсәлән, Иван Янсон «шыгырдавыклы, ямьсез, ләкин артык рәхәт һәм шатлыклы, каз кычкырган шикелле ка-ка-ка иткән тавыш белән кычкырып көләргә тотына»; Мишка Цыганок исә «дүрт аякланып, калтыранган бүре тавышы белән улый».

Асып үтерелгән террористларның мәетләрен натуралистларча тасвирлаган күмәргә алып китү күренеше дә җир өстендәге коточкыч тәмугъны хәтерләтә: «Җансыз тәннәрне ящикларга тутырдылар. Аннан соң алып киттеләр. Сузылган муеннар, гакылдан чы-

гып акайган күзләр, канлы күбек белән сугарылган иреннәр арасыннан күрелмәгән, коточкыч чәчәкләр шикелле, асылып тора торган шешенгән зәңгәр телләр белән, үзләре терек килеш килгән юлдан, җансыз тәннәр кайтып киттеләр».

Әдәбият галимнәре язганча, Леонид Андреевның «Асылган җиде кешеләр» хикәясе реакция елларындагы патша самодержавиесенең революционерларны асу-кисү, төрмәләрдә черетү, җәзалау сәясәтенә гаепләү акты булып торды.

Леонид Андреевның «Асылган җиде кешеләр» хикәясен татарчага тәрҗемә итү Фатих Әмирханның алдагы иҗатында экспрессионистик стильгә корылган әсәрләр тудыру өчен җирлек хәзерли. Язучының Леонид Андреев иҗаты йогынтысында язылган «Татар кызы» (1909) хикәясе моңа дәлил булып тора. Зур гомумиләштерү көченә ия булган бу әсәрдә образ-сурәтләр, сәнгатьчә фикерләү, жанр, композиция, конфликт гәүдәләнеше бик тә үзенчәлекле. Анда урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларына хас кысалы кыйссалар традициясе саклану, эпиграфта һәм хикәянең азагында Коръәндә телгә алынган тереләтә җиргә күмелгән кызлар образы бирелү һәм дә Изге Китаптагыча мөсәҗҗәгъ нәсер (рифмалы проза) стиленә мөрәҗәгать итү рус һәм дә әсәр тукымасына Аурупа әдәбиятларында киң таралган экспрессионистик алымнар һәм экзистенциаль карашлар белән бергә килеп очрашу «Татар кызы» хикәясендә Шәрекъ – Гареб синтезының аерылгысыз, бербөтен тәшкил итүе турында сөйли.

Л. Андреев әсәрләрендәгечә, «Татар кызы» хикәясенең дә тоташ сюжеты юк, анда да кыз баланың яшенә мөнәсәбәттә кино тасмасындагы кебек алмашынып торган күңелсез фрагментлар, кырыс күзәтүләр, авыр хөкемнәр һәм бәяләр генә бар. Татар кызының конкрет исеме дә аталмый; тере колларга әверелдерелгән мөселман хатын-кызлары «җанлы курчаклар», шәригатькә, иске гореф-гадәтләргә турылык саклап, аларны һәлакәт упкынына этәргән аталар образлары «кара көч» символы ярдәмендә гәүдәләнә. Бу үзенчәлекләрнең барысы да – экспрессионистик өслүб билгеләре.

«Татар кызы» хикәясенең эчтәлеген экзистенциализм (латинча: «яшәү») фәлсәфәсе белән дә бәйләп карарга мөмкин. Фатих Әмирхан да татар кызын яшәештә – туу, үсү, мәхәббәт көтү, тормышта борчылу, җәфалану, язмыш сынаулары кебек экзистенциаль чикләр аша үткәрә һәм, ахыр чиктә, аның гомерен үлем белән очлый. Кыскасы, Фатих Әмирхан вакыт һәм хосусиятләр буенча бер-берсеннән бик тә ерак торган мәдәни һәм әдәби традицияләрне янәшә куеп, мөселман һәм Аурупа әдәбиятларының оригинал синтезына ирешә һәм милли алгарышның бик тә актуаль бер алшарты булган хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Ф. Әмирханның А.П. Чехов реализмы рухында импрессионистик алымнардан файдаланып язылган, зыялы яшьләр

тормышын гәүдәләндергән «Урталыкта» (1912) романы һәм «Тигезсезләр» (1914) драмасы да бар. Аларда да импрессионистик әсәрләргә хас булганча, сюжет, вакыйгачылык үзәк урынны алып тормый. Һәр ике әсәрдә дә Фатих Әмирхан үзенең төп игътибарын билгеле бер сюжет кысаларында, төрледән-төрле хәл-әхвәлләрдә кеше җанының киеренке мизгелләрен күрсәтүгә юнәлтә. Геройларның эчке дөньясы алар яшәгән тирәлек, табигать кочагында, утар-дачаларда, мәдәният учакларында аш-су һәм кием-салым, сөйләшү, ничек итеп сәүдә итү, гыйлем алу, һөнәр сайлау тирәсендә барган фикер алышуларда, әдәбият, туган тел, музыка, мәхәббәт, милләткә хезмәт итү, инкыйлабчылык кебек мәсьәләләр турында барган бихисап әңгәмә-бәхәсләрдә ачыла. Бу яктан караганда Фатих Әмирханның прозасын импрессионистларча тирән психологизм, яңа сюжет алымнары, яңа тип герой белән баетуда тәмамланмаган «Урталыкта» романы аеруча игътибарны җәлеп итә. Иң элек бу әсәр XX гасыр башындагы Россия империясендәге һәм татарлар арасындагы иҗтимагый-сәяси халәтне, татар яшьләренең күмәк рәсемен, милли мәдәният мәсьәләләрен яшәешнең төрле мизгелләрен куеп төрледән-төрле сюжетлар бәйләме ярдәмендә сәнгати яктан ышандырырлык итеп чагылдыруы белән кызыклы.

«Урталыкта» романы күләмнәре ягыннан төрлечә озынлыкта булган 16 бүлектән тора. Аларның кайберләре (1, 5, 6, 7, 10, 12, 13) бик тә кыска, кайберләре исә (2, 3, 4, 8, 9, 11, 14, 15, 16) шактый озын. Шушы бүлекләрдә дөньяга карашлары белән бер-берсенә охшамаган дистәләгән Казан яшьләре (унбер егет һәм алты кыз) образы гәүдәләнә. Алар тормышындагы эреле-ваклы вакыйгаларның барысы да әсәрнең баш герое Хәсән Арсланов образы тирәсенә бер фокуска тупланып, үзәк сюжет җебенә бәйләнә.

Хәсән Арсланов уңышлы гына татар мәдрәсәсен тәмамлаган, ихтирамга лаек шәкерт буларак, беркадәр анда пишкадәм вазыйфасын да үтәгән. Әмма мәдрәсәдә алган белемнәренең тормыш итәргә ярамаганлыгын аңлагач та, үзлегеннән русча укырга тотына, аттестат алырга җыена. Мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия бирүнең бик түбән сыйфатлы булуы Хәсәнне «Юләрләр йорты» дигән мәкалә язуга да этәргән. Ул үзенең бөтен барлыгы белән рус мәдәниятенә тартыла. Аның бүлмә диварларына Шекспир, Байрон, Маркс, Пушкин, Тургенев, Толстой, Репин кебек рәссам, язучылар, фикер ияләре рәсемнәре ябыштырылу да аның ауропалашырга теләүче мәгърифәтче һәм җәдитче икәнлеге турында сөйли. Кием-салымны да ул ауропача йөртә; кәләпүш, тужурка киюне «татарщина» дип саный. Русчасы аксаса да, үзен русларга Евгений Петрович дип тәкъдим итә. Әмма Хәсән Арслановның бу «гөнаһлы» адымнары аны руслар белән татарлар арасында буталып калган маргинал тип дип әйтергә хокук бирми. Хәсәннең «татарщина»га каршы чыгуы – һич тә үз милләтеннән йөз чөерүне аңлатмый. Аның

өчен «татарщина» – феодаль җәмгыятьнең искергән традицияләрен, ягъни кадимчелеген кабул итмәү. Хәсәннең милли горурлыгы да җитәрлек. Ул үтә чыккан кызыл эсер Саматовның «Шигырь на татарском языке быть не может!» дигән сүзләренә дә каршы төшә, татар мәдәниятенең, әдәбияты һәм музыкасының киләчәктә үсәчәгенә дә өметләр баглый; Гаяз Исхакыйны «татар тормышының иң зур җәрәхәтен ачучы» «иң зур татар мөхәррире», «иң зур татар таланты» дип атый. Шул ук вакытта ул кайбер татар яшьләренең милли әдәбиятка битарафлыкларын күргәч, каушап та кала, «Юк ла, әдәбият дигән нәрсә татарда булмый ла инде ул» дип, икеләнүле хисләргә, төшенкелеккә дә бирелә.

Романның «Урталыкта» дигән исеменнән күренгәнчә, Хәсән Арсланов көндәлек яшәеш дулкыннарында чайкалучы, бәргәләнүче образ. Ул ата-бабалардан килгән кадими яшәү рәвешен – «татарщина»ны да кабул итми; танышы Саматов кебек үтә радикал инкыйлабчы «таңчылар»ның гамәлләрен дә якламый, үтә сул карашларын да уртаклашмый. Шуңа күрә ул Саматовның аның бүлмәсендә дорфа гына, рөхсәт тә сорамыйча ихтилялга өндәүче революцион эчтәлекле рисаләләр, өндәмәләр, хәреф-шрифтлар, эсерлар партиясе мөһерләр калдырып китүенә җаны сызлана, тәне куырылып киткәндәй була, бәдәне сызлана башлый. Әмма Хәсәннең Саматов турындагы фикерләре импрессионист язучылардагыча үзгәреп, алмашынып тора. Бер яктан, бу бертуктамый кеңкыһ дип борынын тартучы, үзен баһадир итеп күрсәтергә омтылучы, башкалар кулы белән утлы күмер җыярга яратучы Саматовны Хәсән күрә алмый. Аның милли мәнфәгатьләр турында кайгыртуны «татарлык», «позор!» дип тамгалавы өчен дә хурлана. Ә икенче яктан, Саматовның Россиядәге барлык изелгәннәргә, эшчеләргә, сәяси тоткыннарга ярдәм итәргә «общее благо» өчен тырышырга кирәк дигән чакыруларына Хәсән Арсланов күңеленең бер чите белән генә булса да теләктәшлек белодерә. Үткен телле шагыйрь Шәрифнең ирония белән мыскыллы көлүе дә Хәсәндә каршылыклы хисләр уята.

Казанның төрле милләт, төрле холыклы егетләре, кызлары белән очрашулар, әңгәмәләр Хәсән Арслановның рухи халәтен су өстендәге күбек кебек уйнатып, уңга-сулга, алга-артка чайкалдырып тора. Шул рәвешчә, Фатих Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятында импрессионистик стильгә корылган кәеф прозасының беренче сәхифәләрен ачып җибәрә.

Хәсән Арслановның тышкы кыяфәте дә, холкы да матур һәм шыксыз детальләрне, ак һәм кара төсмерләрне импресионист язучылардагыча үзенә туплаган. Бер үк вакытта бу образ индивидуальләштереп тә бирелгән. Хәсән Арслановның дөньяны кабул итүе, эчке дөньясы өчен бер үзенчәлек хас: романның буеннан-буена аның эче поша, кәефсезләнә, үзе-үзен битәрли, Толстой геройларыча вөждан газапларына дучар ителә.

«Урталыкта» романының төп герое турында әдәбиятчылар тарафыннан төрле фикерләр әйтелгән. Ул уңай һәм тискәре образ дип тә, урталыкта торучы образ дип тә бәяләнгән. Әйе, Хәсән образы каралтып та, идеаллаштырып та сурәтләнмәгән. Шул ук вакытта кыйбласы булмаган герой да түгел. Яшәешенә бик еш кәефсезлек юлдаш булса да, ул чамадан тыш кызыл булуын да сөйли, милләтне артка сөйрәүче кадимчеләрдән дә ерак тора. Ул бер чиктән икенче чиккә ташлануны да, «ифрат – тәфрыйть» уеннары уйнауны да өнәми. Хәсән Арсланов иҗтимагый һәм рухи яшәештә Арастуның (Аристотель) «алтын урта» фәлсәфәсе тарафдары. Әмма әлеге дә баягы бер сорау туа: ни өчен соң Ф. Әмирхан үз романын «Урталыкта» дип атаган. Моның сәбәбе: унынчы елларда милли хәрәкәтнең яңа бер чоры башлану, рус революциясе һәм реакция елларындагы сыйнфый һәм революцион көрәш идеяләреннән баш тартып, татар халкының барлык катламнарын бергә туплап, милли аңны үстерү, милли кыйммәтләрне саклау, гомуммилли мәнфәгатьләрне яклау юлына басып, мәгърифәтчеләрчә тыныч урталык юлын сайлап, милли мәдәният һәм мәгърифәтне үстерүгә таба хәрәкәт итә. Мондый фикерләр әдипнең Г. Исхакый «Зөләйхасының сәхнәгә куелу уңае белән язылган тәнкыйть мәкаләсендә дә, публицистик чыгышларында да ассызыклана. Февраль революциясе һәм Учредительный собраниягә сайлау көннәрендә Ф. Әмирханның милли алгарыш турындагы карашлары тагын да ачык сәяси һәм мәдәни төс ала. «Кояш» газетасында «Инкыйлаб вә без» (1917, 19 апрель №1094) дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Милләт арасындагы сыйнфый көрәшне үткенләндерерлек һәрбер хәрәкәт вә һәрбер сүздән сакланып «мәдәни автономия» алу өчен «иң тугры, иң дөрест юл – милләтне бүлендермичә, бер милләт хәлендә сайлауга алып бару юлыдыр».

Ф. Әмирханның тагын бер таҗ әсәре – «Тигезсезләр» (1914) психологик драмасы. Аның сюжет һәм композициясе, табигать, музыка, мәхәббәт мотивлары, образлар системасы, гомумән, әсәрнең бөтен архитектоникасы импрессионистик стильгә нигезләнгән. Пьесаның сюжетында Аристотель заманнарыннан ук кабул ителгән традиционлык – экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш кебек биш элемент берлеге дә сакланмаган. Белгәнебезчә, импрессионистик язучылар вакыйгачылыкка бик аз урын бирәләр, башлыча персонажларның үзара мөнәсәбәтләрен, хис-тойгылар үстерелешен сурәтләүгә басым ясыйлар. Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында да шул ук хәл. Мәсәлән, драмадагы һәр өч пәрдәнең импрессионистларча бирелгән экспозициясе бар. 400 дән артык ремаркалар бирелү дә пьесаның үз режиссурасын булдыра. Хәрәкәт, вакытның сүлпән агышы, вакыйгаларның пәрдә артында, күренешләр арасында баруы, табигать авазлары, музыка, әдәбият,

сәнгать, мәхәббәт турындагы әңгәмәләр, бер яктан әсәрдәге эпиклыкны көчәйтә, икенче яктан, лирик башлангычны арттыра, психологизмны тирәнәйтә.

«Тигезсезләр» драмасындагы төп образларның берсе – яңа заман сәүдәгәре, акыллы һәм талантлы эшкуар Гомәр. Пьесада ул төрле мизгелләрдә, төрле халәтләрдә гәүдәләнә һәм образлар системасын психологик яктан гына түгел, социаль күзлектән дә бер җепкә бәйләп торучыга әйләнә. Шуны да әйтергә кирәк, социаль мөнәсәбәтләр турындагы фикерләр пьесада, башлыча, Гомәр авызыннан әйттерелә һәм алар әсәр тукымасына импрессионистларча сиздермичә, юл уңаенда гына кертеп җибәрелгән тәэсир калдыра. Аларның кайберләрен искә алып үтик. Мәсәлән, Гомәр, Печән базарындагы татарлар кебек, он-тоз, читек-кәвеш белән генә алыш-биреш итү тарафдары түгел. Ауропадагы кебек, мәдәни бизнес вәкиле буларак, ул югарырак баскычка үрмәли: оптика кибете ачып җибәрә, немецлар, яһүдиләр кебек зурдан кубып сәүдә итү турында уйлана. Гаилә һәм милләт мәнфәгатьләрен дә онытмый. Сеңлесе Сәлимәне немец телен һәм бухгалтерияне үзләштереп, сәүдә эшенә керешергә өнди. Кече сеңлесе Рокыяга да юридик факультетта укырга киңәш бирә, чөнки «юрист һәрвакыт үз-үзен туендыра ала». Гомәр хатын-кыз хокуклары турында да уйлана. Аныңча, икътисади яктан тәэмин ителгән хатын-кызлар гына гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә азат һәм бәхетле була алалар. Хатын-кыз язмышын икътисади азатлык мәсьәләсе белән бәйләп, уңай якка үзгәртү мөмкинлеге беренче мәртәбә Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» антиутопиясендә әйтелгән иде. Икенче мәртәбә бу мәсьәлә гендер теориясе күзлегеннән әһәмиятле социаль проблема буларак Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында көн тәртибенә куелды. «Минемчә, – ди пьеса герое Гомәр, – татар кызларын үз көннәрен үзләре күрерлек кешеләр итеп тәрбия итәргә кирәк. Шул вакытта гына алар ирләре кулына карап тормаслык бөтенләй хөр була алалар».

Драмада импрессионистик рәссамнар кебек ачык буяулар белән оста тасвирланган образларның икенчесе – гүзәл кыз Рокыя. Ул – шаян, саф күңелле, җор телле, үз ирке, үз ихтыяры белән яшәргә омтылучы иркә җан. Тирә-юньдәге, гаиләдәге һәр кеше аны ярата. Рокыя рус гимназиясен тәмамлаган; рус һәм татар әдәбиятын яхшы белә, рәссам булу турында хыяллана; пианино артына утырып, өздереп «Вальс», «Мөхәммәдия» көйләрен уйный. Табигать аңа матурлыктан да мул өлеш чыгарган; егетләр дә аңа гашыйклар. Рокыя – чәчләренә чал төшкән шагыйрь Сөләйманның да идеалы, намаз укыганда нурлар диңгезендә йөзүче фәрештәсе. Әмма мәхәббәттә алар – «тигезсезләр», чөнки Рокыяның гүзәллеге, бәхетле яшьлеге – шактый олы яшьтә булган Сөләйманның сагышы, йөрәк ярасы, киеренке кичерешләре. Абыйсы Гомәр кебек, Рокыя образы да пьесадагы сюжет җепләрен бер фокуска җыеп, бәйләп тора.

Драманың ике фокуслы булуы – шулай ук авторның импрессионистик стиль чараларына мөрәҗәгать итүдән туган күренеш.

Ф. Әмирханның башка әсәрләрендәге кебек, «Тигезсезләр» драмасындагы яшьләр образлары да кайсыдыр бер сыйфатлары белән индивидуальләштерелеп бирелә. Мәсәлән, «страховой агент» Закир образы курсисткаларга, туташларга, егетләргә сөйләгән мәзәкләр – кара юмор ярдәмендә ачыла. Ул сөйләгән тозсыз мәзәкләр, мәгънәсез фокуслар яшьләрнең күңелен төшерә, авыруга сабыштыра, куркуга сала. Рус әдәбиятында мондый «кара юмор» элементларына А.П. Чехов еш мөрәҗәгать иткән иде. Аның иҗаты аша яшәешнең күңелсез мизгелләрен импрессионистларча кечкенә сюжетларда тасвирлаган, тупас күңел ачуга корылган «кара юмор» Ф. Әмирхан иҗатына да үтеп кергән.

Ф. Әмирханның татар модернистик әдәбияты үсешенә керткән яңалыклары, сәнгати ачышлары рус әдәбиятындагы «Көмеш гасыр» («Серебряный век», икенче атамасы – Ренессанс) вәкилләре эшчәнлеген хәтерләтте. Рус мәдәниятендә һәм әдәбиятында бу модернизм әдәбиятына таба зур борылышны И. Анненский, К. Бальмонт, А. Блок, А. Белый, И. Бунин, А. Ахматова, Н. Гумилев, Ф. Сологуб, Д. Мережковский, Вяч. Иванов, А. Куприннар кебек көчле бер төркем башлап җибәрсә, татар Яңарыш әдәбиятында моңарчы мәгълүм булмаган, күз алдына китерү дә авыр инкыйлабка тиң иҗади эшне Фатих Әмирханның берүзенә башкарырга туры килде.

Илне канга батырган Октябрь түнтәрелеше, гражданнар сугышы, Идел буендагы ачлык афәте, рәхимсез сыйнфый көрәш һәм атеистик сәясәт авыру Ф. Әмирханның көндәлек яшәешендә, әдәби эшчәнлегендә зур кыенлыклар тудырды. Шуңа да карамастан, иҗат эшен туктатмады, бик тә тирән фәлсәфи эчтәлекле ислам дине, Коръән тәгълиматы өйрәтмәләренә таянып яшәү һәм үлем фәлсәфәсен яктырткан экзистенциаль мотивлар белән сугарылган атаклы «Тәгъзия»сен (1922) язды, пролетариат диктатурасы елларында марксистик-ленинчыл идеология белән агулануның классик үрнәге, концептуализм дигән модерн юнәлешенә караган «Шәфигулла агай» пародиясен иҗат итте. Кыскасы, Габдерахман Сәгъди сүзләре белән әйткәндә, «Ничек булганда да, Ф. Әмирхан һәр ягы белән татарның классик буржуаз әдипләренең берсе булып, татар әдәбиятында зур урын тотты һәм татар әдәбиятының иң көчле бер гамиле (хөкемдары) булды» [Сәгъди, б. 380].

**Әдәбият**

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. Казан, 1926. (кульязма).
Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 41.

***Ганиева Резеда Кадыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*